МИРАС ТӨРЛЕЛЕГЕ

Җәмгыять рухын ныгыту хәзер аеруча кирәк

> 2

АК ҖИЛКӘН

90 яшен тутырган Лирон Хәмидуллинның тормыш сәхифәләре

> 3

ЯЗУЧЫ СҮЗЕ

«Үсим генә... Үземә үзем хуҗа булам!»

> 4



ЛЕГЕНДАР ЩЕПКИНЧЫ

Татар җәмәгатьчелеге Наил Дунаевны соңгы юлга озатты

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 162 (28935) | Чәршәмбе | 2 ноябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

БУРЫЧ БЕЛӘН КИТМИЛӘР

Мобилизациягә эләккән егетләргә матди ярдәмнән тыш ташламалар да вәгъдә итәләр. Алар һәм гаиләләре кредит каникулыннан файдалана ала, транспорт салымыннан азат ителә. Ватан алдында бурычын үтәүчеләргә тагын нинди өстенлекләр каралган? Хөкүмәт йортында узган брифингта алар турында тәфсилләбрәк сөйләделәр.

Мобилизациягә эләккән кешеләр иң элек кредит түләүдән вакытлыча азат ителә. Закон нигезендә алар кредит каникулы алырга хокуклы. Бу мөмкинлектән махсус операциягә үз теләге белән киткән кешеләр дә, анда контракт буенча хезмәт итүчеләр дә файдалана ала.

Татарстанның икътисад министры Мидхәт Шаһиәхмәтов сүзләренә караганда, кредит каникулы Ватан алдында бурычын үтәргә киткән ир-аттан тыш, аның гаиләсе – ата-анасы, тормыш иптәше һәм балаларына да бирелә. Кредит суммасы һәм аның әҗәтнең ничә банктан алынган булуы мөһим түгел. Әлеге канун 7 октябрьдә үз көченә керде. Шул вакыттан бирле республиканың кредит оешмалары 620 миллион сумнан артык суммадагы кредит буенча түләүләрне кичектереп торырга рөхсәт иткән.

– Кредит каникулыннан банкка әҗәткә акча алган кешеләр генә түгел, кулланучы, авыл хуҗалыгы кооперативларына бурычы булган, ломбардка мөрәҗәгать иткән кешеләр дә файдалана ала. Бу мөмкинлек физик затларга гына түгел, мобилизация яки контракт нигезендә хәрби хезмәткә киткән шәхси эшмәкәрләргә дә бирелә, – диде министр.

Кредит каникулын алу өчен гаризаны киләсе елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча тапшырырга кирәк. Аны оешманың үзенә барып та, онлайн рәвештә дә язарга мөмкин.

– Кредит каникулын аерым төрдәге бурычы булган кеше генә алырга мөмкин дигән чикләү юк. Ул ипотека,

pnp.ru

кулланучы кредиты булган, мобилизациягә кадәр кредит карталарыннан файдаланган кешеләргә дә бирелә, – дип ачыклык кертте Мидхәт Шаһиәхмәтов.

Тагын шунысы да бар: кредит буенча түләүләрне вакытлыча кичектереп тору мобилизациягә эләгүчеләр һәм якыннарының кредит тарихына һич кенә дә йогынты ясамаячак. Димәк, киләчәктә яңа төр кредит рәсмиләштерә калсалар, кыенлыклар килеп чыгачак дип куркасы да юк. Закон нигезендә, кредит каникулы дәвам иткән чорда заемчыга килешү шартларын үтәмәгән өчен штраф салырга, пеня өстәргә дә ярамый.

– Физик затларга бирелгән кредит каникулы – мобилизация тәмамлангач, тагын 30 көн, юридик затларныкы – мобилизация тәмамлангач, тагын 90 көн гамәлдә булачак. Бу вакыт чыгуга, кредит каникулы алган затка кредит оешмасына мөрәҗәгать итәргә туры киләчәк. Аннары кредит түләүнең яңа графигын төзеячәкләр, – ди «Ак Барс» банк идарәсе рәисе урынбасары Радик Сәләхетдинов.

Мобилизациягә эләгүчеләргә салым түләү буенча да өстенлекләр каралган. Закон нигезендә алар узган ел өчен транспорт салымы түләүдән азат ителә. Әмма техника саны бердән артмаска тиеш. Калганнары өчен түләргә туры киләчәк. Транспорт салымыннан котылу өчен дә гариза язасы түгел. Барысын да оешмалар арасындагы мәгълүмат алмашу юлы белән хәл итәчәкләр.

– Хәзер узган ел өчен милек салымы түләр чак та җитте. Мобилизациягә эләккән кешеләргә моңарчы килгән түләү хатлары үз көчен югалта. Аларны түлисе түгел. Салымны түләү вакыты кичектерелгән яңа хатлар соңрак җибәреләчәк, – диде Салым федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе Марат Сафиуллин.

Мобилизациягә эләккән эшмәкәрләрдән дә декларация тапшыру, салым түләү таләп ителмәячәк. «Мобилизациягә эләккән эшмәкәрләрне салым органнары да тикшереп интектермәячәк, аларның счетларына «блок» та куелмаячак», – дип ышандырды идарә башлыгы. Ватанны сакларга киткән эшмәкәрләр хәрби бурычын үтәгән чорда федераль милекне арендалаган өчен түләүдән дә азат ителәчәк. «Җирле хакимиятләргә муниципаль милек өчен аренда түләүләрен дә кичектереп тору мөмкинлеге бирүләрен сорап мөрәҗәгать иттек», – ди Татарстанның җир һәм милек мөнәсәбәтләре министры урынбасары Артур Галиев.

Эшмәкәрләрнең мобилизациягә кадәр откан грантларының гамәлдә булу вакытын да туктатып торачаклар. «Грантның күләме үзгәрмәячәк. Аны куллану вакыты исә озайтылачак. Теләге булса, мобилизациягә эләккән эшмәкәр аннан штраф түләмичә генә баш тарта да ала», – дип ачыклык кертте Мидхәт Шаһиәхмәтов.

Сорау – җавап

? Өлешчә мобилизациягә эләккән кешеләргә түләнәсе 195 мең сумлык пособиедән салым тотыламы?

– Юк, бу акчадан салым тотылмаячак.

? Банк мобилизациягә эләккән кешегә кредит каникулы бирүдән баш тарта аламы?

– Банк Оборона министрлыгы әлеге затның мобилизациядә катнашуын рәсми рәвештә расламаган очракта гына кешегә кредит каникулы бирүдән баш тарта ала.

? Мобилизациягә эләккән кешеләргә җир һәм милек салымы түләгәндә дә ташламалар ясалачакмы?

– Закон нигезендә бу мәсьәләне муниципаль хакимият органнары хәл итәргә тиеш. Әлегә бу яңалык Чаллы шәһәрендә генә гамәлгә керергә охшап тора.

Ком һәм тоз хәстәре

Кышын Татарстандагы федераль юлларда бозлавыкка каршы 147 мең тонна материал, шул исәптән 118 мең тонна ком, 29 мең тонна тоз әзерләп куелган. «Волго-Вятскуправтодор» хәбәренә караганда, хәтәр чокырларны вакытында «ямау» өчен салкын асфальт-бетон хәстәре күрелгән. Кышкы көннәрдә трассаларны карап тоту максатында 377 берәмлек юл техникасы, шул исәптән 37 кар чистарткыч, 47 кар төягеч һәм экскаватор, 23 бульдозер һ.б. эшкә керешергә тулысынча әзер. Барлык техника да ГЛОНАСС белән тәэмин ителгән.

Моннан тыш юлларга сибү өчен 24 ком өеме, техника өчен 30 җылы тукталыш, йөртүчеләрне ял иттерү өчен 23 бүлмә булдырылган. Һава торышы бозылган көннәрдә юлның катлаулы – таулы өлешләрендә авыр техника дежур торачак. Татарстанда шундый 17 участок бар. Шуның 7се – М7 юлында, 5есе – М7дән Киров өлкәсенә таба борылганда, 3есе – Казан – Буа – Ульяновск һәм 2се – Казан – Оренбург трассаларында.

Татарстанның ЮХИДИ идарәсе көпчәкләрне кышкыга алмаштырырга, һава торышы бозылганда бик кирәк булмаса, шәһәр һәм авыллардан чыгып йөрмәскә, юл кагыйдәләрен үтәргә киңәш итә.

Кимүгә бара

Россиядә коронавирус йоктыручылар саны алтынчы атна рәттән кими. Роспотребнадзор сайтында шул хакта хәбәр ителгән. Узган атнада илдә COVID-19 инфекциясен ияртүнең 49243 очрагы теркәлгән. Чирләүчеләр саны 100 мең кешегә 33,56 күрсәткечен тәшкил иткән (алдагы атнадагы белән чагыштырганда 12 процентка кимрәк). Шул ук вакытта 38 төбәктә авыручылар саны уртача күрсәткечтән артыграк икән.

Моннан тыш ОРВИ йоктыручылар сафы да сирәгәя. Роспотребнадзор А, В гриппы вирусы белән авыруның берничә очрагын теркәгән. Бүгенгә Россиядә яшәүчеләрнең 45,5 миллионнан артыграгы грипптан прививка ясаткан. Бу – барлык халыкның 31 проценты дигән сүз.

Сүз уңаеннан, соңгы тәүлектә Татарстанда 135 кеше (алдагы көнне – 140) коронавирус йоктырган.

5 процентка төшкән

Россиядә ярты ел эчендә (апрельдән октябрьгә кадәр) инфляция 5 процентка кимегән. Премьер-министр Михаил Мишустин Шанхай хезмәттәшлек оешмасы (ШОС) хөкүмәтләре башлыклары советы утырышында белдергәнчә, апрель аенда инфляция 18% чамасы булса, октябрь аенда 13% тәшкил иткән.

Шул ук вакытта гыйнвардан августка кадәрге чорда ШОС дәүләтләре белән сәүдә күләме өчтән бер өлешкә зураеп, 156 миллиард доллардан артып киткән. «Алга таба да мөмкин булганның барысын да эшләячәкбез, барлык юнәлешләр буенча тырышлыкны көчәйтәчәкбез», – дигән Премьер-министр.

Актуаль мәсьәлә

Мобилизация түгел

КӨЗГЕ ЧАКЫРЫЛЫШТА АРМИЯГӘ КИТҮЧЕЛӘР МАХСУС ХӘРБИ ОПЕРАЦИЯДӘ КАТНАШМАЯЧАК

Россиядә көзге чакырылыш башланды. Мәгълүм сәбәпләр аркасында, быел аны бер айга кичектерделәр. Татарстанның хәрби комиссары Сергей Погодин «Татар-информ» агентлыгы белән әңгәмәсендә быелгы чакырылышның үзенчәлекләре турында сөйләгән.

ӨЧ МЕҢЛӘП ЕГЕТ КИТӘ. 1 ноябрьдән хәрби хезмәткә чакырылыш башланды. 49 хәрби комиссариат үз эшен башлап җибәрде. Егетләрне гаскәрләргә җибәрү исә ноябрьнең беренче декадасында ук башланачак. Россия Кораллы көчләренең генераль штабы ассызыклаганча, чакырылыш чаралары махсус хәрби операция барышына берничек тә бәйле түгел. Көзге чакырылыш, элеккечә һәм гадәттәгечә, закон кысасында һәм планлы рәвештә алып барыла. Хәрби хезмәткә чакырылган егетләр махсус хәрби операциядә катнашмаячак. Хезмәт итү срогы тулган хәрбиләр өйләренә кайтарылачак.

Татарстаннан быел 3 меңләп кеше хәрби хезмәткә чакырылачак. Бу былтыргы саннан бераз кимрәк тә.

КАЙСЫН САЙЛАРГА? Хәрби хезмәткә чакырылучы кайсы гаскәрдә хезмәт итәсен үзе сайлый аламы, дигәннән, аны кая җибәрү турында карарны комиссия хәл итә. Бу очракта гаскәрләрнең ихтыяҗы да, хәрби хезмәткә чакырылучының сәламәтлеге, хәрби белгечлеге, белеме, әзерлеге, психологик халәте дә исәпкә алына. Чакырылышка беренчеләрдән булып килгәннәргә өстенлек бирелә. Аларга сайлау мөмкинлеге дә киңрәк булачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Балалары, авыру туганнары һәм өлкән яшьтәге ата-анасы булган егетләргә исә яшәгән урынына якынрак җирдә хезмәт итү мөмкинлеге тудырылачак.

СӘЛАМӘТЛЕККӘ – ЗУР ИГЪТИБАР. Хәрби хезмәткә чакырылучылар, җыелу пунктына килүгә, ике мәртәбә коронавируска тикшерү узачак. Бөтен кирәк-яраклар да бар.

ӨСТӘМӘ МӘГЪЛҮМАТ. Россия Оборона министрлыгының рәсми сайтында актуаль мәгълүмат белән танышырга мөмкин. Моннан тыш республиканың рәсми интернет-порталындагы «Татарстанның хәрби комиссариаты» бүлегендә, «Объясняем.рф» сайты һәм «122» номеры аша кирәкле мәгълүматны табарга була. Хәрби чакырылышны үткәрүгә барысы да әзер.

Сүзгә-сүз

Максут ШАДАЕВ, Россиянең цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министры:

Без киткән хезмәткәрләргә карата кискен чаралар куллануга каршы. Киресенчә, кире Россиягә әйләнеп кайту теләге тудырырлык шартлар булдырырга кирәк. Безнең бурыч – релокация программасын әзерләү һәм монда эш мөмкинлекләренең киң булуын гамәл белән раслау.

ТАТАРСТАНДА – ХЕЗМӘТ ХАКЫ

Сез хезмәт хакыгыздан канәгатьме? «HeadHunter» хезмәте белгечләре Татарстанда яшәүчеләрдән шул хакта сорашкан. Канәгатьсезлек күбрәк куркынычсызлык, фән, мәгариф, медицина тармакларына карый икән. Матди яктан канәгатьлек хисе файдалы казылмалар чыгару, сәүдә, менеджмент, консультация бирү өлкәләрендә эшләүчеләргә хас.

Көзге ял

Көзге каникул чорында Татарстанның 342 лагеренда 18 меңнән артыграк бала сәламәтлеген ныгытачак. Аларның күбесе мәктәп яны лагерьларында ял итә, укучылар шулай ук предприятие-оешмалар, муниципаль һәм республика лагерьларына юл тота. Яшьләр эшләре министры урынбасары Ринат Садыйков билгеләп үткәнчә, ял итү-савыктыру оешмаларына мобилизацияләнүчеләрнең балалары да урнаштырыла. Бүгенгә шундый 63 бала ял итә икән. Аның әйтүенчә, укучыларны тукландыруны, саклауны оештыру, санитария нормаларын үтәү – аерым игътибар үзәгендә. Лагерьларда төрледән-төрле мәгариф, мәдәни программалар каралган. Аларда Халыклар бердәмлеге көненә, Татарстан Конституциясенә багышланган чаралар үткәреләчәк. «Ял иткәндә, яшьтәшләре, вожатыйлары белән аралашканда, төрле программаларда катнашканда, баланың үсешенә уңай йогынты ясала. Шуңа күрә лагерьлар эшчәнлеген даими рәвештә барлап торабыз», – ди Ринат Садыйков.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

БЕР КАЗАНДА – ИКЕ ТӘКӘ БАШЫ

Дөнья сәясәтенә игътибар белән карасак, без күптән инде дәүләтләрнең үзара сугышуын-тартышуын күрер идек. Башта валюта сугышлары оештырдылар. Аларның асылы илләрнең үз валюталарын махсус рәвештә йомшартудан тора. Моның белән аеруча Кытай мавыкты. Юань арзанайганда, чин товарлары да арзанлы була, димәк, экспорт арта. Эчке базар өчен бер файдасы да юк моның, киресенчә, импортның кыйммәтләнүе хисабына инфляция үсә, әмма бюджет өчен яхшы, эш урыннары булдыруга да хезмәт итә. Валюта сугышына соңрак башка дәүләтләр дә кушылды һәм ул үзенең мәгънәсен югалтты.

Америка дилбегәсе Трамп кулына эләккәч, акчалар бәрелешен сәүдә сугышлары белән алыштырдылар. Хәтерлик әле: Трамп Кытайга һәм Европага үз газын, нефтен алдырырга теләп бәйләнде. Тегеләрнең товарларын Америкага кертмәскә тырышты, пошлиналар салып җәфалады. Бу юл белән дә ерак китеп булмый. Технологик яктан алга киткән дәүләтләр сыйфатлырак һәм арзанлырак товарлар белән базарга барыбер үтеп керә. Базарда чит ил товарлары өстенлек итә башласа, акчаң чүпкә әйләнә, чималдан башка берни дә сата алмыйсың, хәрби куәтең югала, үзең белән исәпләшмиләр. Американнар бик тиз аңлап алды моны. Бүген хәтта гарәп монархияләре дә Байденның бармак янавына төкереп кенә карый. Кытайга якынаялар. Нефтьне долларга түгел, юаньга сатарга күчеп маташалар. Ниһаять, Вашингтонда аңлап алдылар: үз технологик гигантларына Кытайда җитештерү мәйданнары ачарга рөхсәт итеп, нык ялгышканнар. Икътисади яктан аякка баса башлагач, чиннар үз технологияләренә гигант инвестицияләр ясады, хәрби куәтләрен арттырырга тотынды. Һәм Си соңгы съездда «биполяр дөнья» турында игълан итте, ягъни дөньякүләм хакимлек ике держава – АКШ һәм Кытай кулында булачак. Башкалар шулар кубызына биергә тиешләр. Беләбез бит инде: бер казанга ике тәкә башы сыймый. Болай барса, озаклламый Пекин үзен гегемон дип тә игълан итәчәк һәм Вашингтонны үз табаны астына салырга тырышачак.

Пекинның амбицияләрен авызлыкламасаң, эшләрнең начар буласын аңлаган американнар соңгы чараны мәйданга чыгарды. Технологик сугыш игълан ителде. Кытай технологик компанияләрендә эшләүче АКШ гражданнарына һәм бизнесына чикләүләр кертелде. Күк асты иленә технологик товарлар сату тыю дәрәҗәсенә якынайтып чикләнде. Хәзер АКШтан Кытайга заманча чиплар җитештерү өчен кирәкле җиһазлар сату да рөхсәт ителми. Әмма чаралар соңгарак калды. Кытай технологик яктан үсешен дәвам иттерә. Берникадәр зыян күрә, билгеле. Бердәнбер уен картасы – сугыш белән куркыту көн тәртибенә килеп басты. Американнар бүген үз хәрби куәтләрен Күк асты иленә якын урнаштыру юнәлешендә тиңсез адымнар ясыйлар. Австралиянең төньягында B-52 бомбага тотучы очкычларын һәм башка самолетларны урнаштыру өчен база төзи башладылар. Аларның андый базалары Тын океандагы Гуам утравында бар инде. Әмма ул базага чин баллистик ракеталарының буе җитә. B-52 очкычлары исә, ерактан торып, канатлы ракеталар ата, хәтта бомба да ыргыта алалар. Һәрберсе 32 тонна хәрби йөк күтәрә ала. Зур сугышка әзерлек башка юнәлешләрдә дә бара. Ләкин державалар икесе дә икътисади кризис йөгеннән егылыр, дип уйлыйм мин. Эш үзара бәрелешкә үк барып җитмәс.

Россиядә

ҮЗЕҢНЕКЕ – ҮЗӘКТӘ

Карабах проблемасын хәл итү өчен, Алиев, Пашинян, Путин катнашындагы өчьяклы очрашу төбәк конфликтларын, җир мәсьәләсен хәл итүнең авыр һәм катлаулы икәнен күрсәтә.

Россиянең конфликтка кергән якларны килештерү мөмкинлеге бүген чикләнгән. Очрашу уңышлы төгәлләнде дип саналса да, уртак белдерүдә: «…Лидеры России, Армении и Азербайджана условились продолжить поиск взаимоприемлемых развязок, РФ будет оказывать этому всяческое содействие…» – дигән пункт низагны төенләү генә җиңел, чишү кыен икәнне дәлилли. Шуңа күрә матбугат очрашуында Карабах темасы гына түгел, Россия алдында торган проблемаларның да кискен күтәрелүе, шул темага сорауларның күп яңгыравы гаҗәп түгел. «Ашлык килешүе» мәсьәләсе дә, мобилизация темасы да, Украина белән сөйләшүләр, газ экспорты турындагы сорауларның күтәрелүе дә ачык күрсәтә: көнбатыш чикләрдәге конфликт безнең авырткан җиргә әйләнде. Дәүләт Думасы спикеры Володин үзенең telegram-каналында «ашлык килешүе»нә кире кайтып булмавы хакында язса, Путин мәсьәләне алай кискен куймады. «Килешү»нең туктатып кына торылуын әйтте. Лидер позициясе отышлырак, билгеле, чөнки Украина ашлыгы белән сәүдә итү темплары бик нык акрынайса да, дәвам итә бит. Ашлыкны төрек кораблары сагы астында чыгаралар, БМО булыша. Әлегә кадәр ашлык төягән корабларны Россия тикшерүчеләре катнашында карап озаталар иде, «килешү»дән чыксаң, бу мөмкинлек бетереләчәк. Сәүдәгә аяк чалам дип, төрек хәрби корабларына һөҗүм итмәссең бит инде. Шуңа күрә, ихтимал, Мәскәүнең якындагы көннәрдә килешүгә әйләнеп кайтуын көтәргә кирәктер.

Төркия – Россия өчен бүген иң әһәмиятле илләрнең берсе. Хәтта газ сәүдәсен дә шуның аша йөртергә өметләнәбез. Дөрес, газ сәүдәсен төрекләр кулына тапшыру икътисади яктан бик үк файдалы түгел. Әнкара бүген үк инде шартлар куя: газга түләүләрне кичектерүне сорый, бәяне 25 процентка түбәнәйтүне таләп итә… Торба сузылса, таләпләр тагын да кискенрәк булачак, моны Кремльдә дә аңлыйлар. Әмма кая барасың? Газны кире җир тишегенә тутыра алмыйсың бит.

Миңа Путинның «партнерлар» дигән сүзе ошый. Соңгы вакытларда ул аны еш әйтә башлады. Дус булмаган илләр дә – «партнерлар», хәтта «украин партнерлар» дигән сүзтезмә дә ишетелде авызыннан. Бу карашларның уңай якка үзгәрүен күрсәтә, амбицияләрдән баш тартып, «әйдәгез, дус яшик» дигән сигнал бирүгә күчү күзәтелә. Бик яхшы трансформация бу. Әмма каршы якта тәкәббберлек үсә. Путин Киев белән ихтимал булган сөйләшүләр турында: «Россия не будет заранее выкладывать на стол свою переговорную позицию по Украине», – диде. Төп мәсьәлә шул бит инде: «переговорная позиция». Ике якның менә шул «позиция»се туры килми торып, сөйләшү дә, килешү дә була алмый.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

ӨМЕТЛӘР АКЛАНДЫ

Ислам дине Россия дәүләтчелегенең, тарихының һәм мәдәниятенең аерылгысыз өлеше булып тора. Идел Болгарстанында ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга әзерлек һәм аны уздыру буенча оештыру комитетының йомгаклау утырышында Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин шулай дип белдерде. Очрашу Мәскәүдә узды. Чарада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

tatarstan.ru

Марат Хөснуллин ассызыклаганча, әлеге мөһим вакыйгага бәйле чаралар федераль дәрәҗәдә оештырылды. Ел дәвамында әһәмиятле эшләр башкарылды: дини-гыйльми хезмәтләр басылды, күргәзмә, фәнни конференцияләр оештырылды.

– Россия Президенты Владимир Путин илебез мөселманнарының дәүләт үсешен тәэмин итүгә керткән зур өлешен берничә тапкыр билгеләп үтте, – диде Марат Хөснуллин. – Бүген ислам Россия дәүләтчелегенең, аның тарихы һәм мәдәниятенең аерылгысыз өлеше булып тора. Аның тарафдарлары – дистәләгән миллион Россия гражданнары.

Марат Хөснуллин сүзләренчә, оештырылган барлык чаралар да киеренке вазгыятьтә үтте. «Көнбатыш җәмәгатьчелеге Россияне кимсетсә дә, без ислам дөньясыннан ярдәм булуын күрәбез. Мөселман илләре вәкилләренең «KazanSummit – 2022» халыкара икътисади чарасында актив катнашуы да моңа бер дәлил булды», – диде вице-премьер.

Төп чаралар, билгеле, Татарстанда узды. Рөстәм Миңнеханов үз чыгышында әлеге чараларны уздыруда ярдәм һәм теләктәшлек күрсәткән өчен Россия Президенты Владимир Путинга, ил Хөкүмәтенә рәхмәтен җиткерде.

– Юбилей елы ил өчен бик үк җиңел булмаган чорга туры килде. Украинада коралды каршылык һәм Россиягә карата моңарчы күрелмәгән басым безнең барыбыз өчен дә җитди проблемага әйләнде. Шуңа да карамастан, Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу кысасында билгеләнгән барлык чаралар да югары дәрәҗәдә үтте. Татарстан федераль хакимият органнары үзәкләштерелгән мөселман оешмалары белән тыгыз элемтәдә эшләде. Шунысы куанычлы: ислам дөньясы илләре бу катлаулы чорда да Россия белән элемтәләрне өзмәде, – диде республика Президенты.

Рөстәм Миңнеханов бәйрәмнең күпмилләтле илнең тарихи елъязмасында тагын бер якты сәхифә булып калачагына, җәмгыятьтә дин һәм милләтара тынычлыкны һәм татулыкны ныгытуга ярдәм итәчәгенә ышаныч белдерде. Татарстан Президенты оештыру комитетына, хәзрәтләргә һәм ярдәм иткән кешеләргә рәхмәт әйтте.

Рөстәм Миңнеханов Мәскәүдә Россия сәнәгатьчеләр һәм эшмәкәрләр берлеге президенты Александр Шохин белән очрашты. Очрашуда әлеге оешма, Татарстан Хөкүмәте, республиканың предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе арасында хезмәттәшлек турында килешү имзаланды.

ЗУР ХЕЗМӘТНЕҢ ӘҖЕРЕ

Мәдәни мирас, рухи байлык дигәндә, битараф кешеләр аз. Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе археологик агачны реставрацияләү мәсьәләләренә багышланган халыкара конференциядә катнашты. Минтимер Шәймиев «Яңарыш» фонды эшчәнлеге һәм республиканың ЮНЕСКО белән хезмәттәшлеге турында сөйләде.

Республикада соңгы 10 елда мәдәни мирасны торгызу, саклау эшләренә аерым игътибар бирелә. Россия өчен дә бу төп бурычларның берсе санала. Халыкара конференциянең Россиядә яшәүче халыкларның мәдәни мирасы елында һәм Татарстанда Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгында узуы да очраклы түгел. Сүз уңаеннан, әлеге чарада Россия, Төркия, Казахстан, Үзбәкстан, Сүрия, Монголия, Сенегал, Белоруссия, Кытай, Һиндстан, Азәрбайҗаннан 100дән артык белгеч катнаша. Алар өч көн дәвамында агач, күн һәм башка органик материаллардан археологик предметларны реставрацияләү, саклау һәм экспонатлаштыруга бәйле мәсьәләләр буенча фикер алышыр дип көтелә.

– Күпмилләтле халкыбызның тарихи мирасын торгызу эшендә «Яңарыш» фонды аша бик күп хәйриячеләрнең катнашуы куанычлы. Казан Кремленең, Болгар тарих-археология комплексының, шулай ук Зөя утрау-шәһәрчегендәге Успение соборы һәм монастыреның ЮНЕСКО Бөтендөнья тарихи-мәдәни мирас исемлегенә кертелүе – әлеге искиткеч зур хезмәтнең нәтиҗәсе. Без исә Идел буе федераль округыннан әлеге исемлеккә кертелгән өч объектның да Татарстанда булуы белән горурланабыз, – диде Минтимер Шәймиев.

Дәүләт Киңәшчесе искәрткәнчә, әлеге мәдәни мирас объектларына карата халыкның да кызыксынуы көчле. Моны саннар да дәлилли. Әйтик, Болгар һәм Зөягә генә дә быел 1,6 млн турист килгән.

– Безгә Идел буе халыкларының бай мәдәни мирасын саклауда актив катнашу, аны арттыру һәм яшь буынга тапшыру бурычы йөкләнде, – диде ул.

Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев Россия тарих җәмгыяте идарәсе рәисе, «Ватан тарихы» фонды башкарма директоры Константин Могилевский, Россия тарих җәмгыяте президиумы әгъзасы Николай Макаров, шулай ук Азәрбайҗан Милли Фәннәр академиясе академигы Шахин Мостафаев белән очрашты. Очрашу барышында урта һәм югары мәктәптә тарихи белем бирүне үстерү мәсьәләләре буенча фикер алыштылар. Кунаклар буш кул белән килмәгән иде. Константин Могилевский Минтимер Шәймиевкә Татарстан һәм Россиянең тарихи-мәдәни мирасына игътибарлы һәм сакчыл мөнәсәбәте өчен Россия тарих җәмгыяте рәисенең Рәхмәт хатын тапшырды. Минтимер Шәймиев исә кунакларны «Яңарыш» фондының Рәхмәт хатлары белән бүләкләде.
Сүз уңаеннан, очрашу барышында КФУ ректоры Ленар Сафин Дәүләт Киңәшчесенә КФУ бүләген – Френ алтын медален тапшырды.

Бергә булыйк!

Мәскәүдә чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызның Бөтендөнья конференциясе узды. Анда дөньяның 84 иленнән иҗтимагый берләшмәләр лидерлары, Россия сенаторлары, Дума депутатлары катнашты. Төп тема – икътисади хезмәттәшлек.

Дәүләт Советы Рәисе – республика Президенты каршындагы Ватандашлар эшләре буенча координация советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Татарстанның чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез белән берлектә эшләү тәҗрибәсе турында сөйләде.

Россия банкы мәгълүматларына караганда, узган елда Татарстанга чит илләрдән 388 миллион доллар күләмендә инвестиция алынган. Бу – 28,6 миллиард сум дигән сүз. «Безнең өчен аз акча түгел. Ә иң мөһиме – яңа бәйләнешләр, бизнес өчен яңа мөмкинлекләр. Быел да бу юнәлештә актив эшләргә ниятлибез. Санкцияләр китергән кыенлыкларга карамастан, җитештерү күләмен киметмәдек», – диде Фәрит Мөхәммәтшин утырышта.

Ул ватандашларыбызны ил төбәкләренә күчерү буенча федераль программаны тормышка ашыру мәсьәләсенә аерым тукталып үтте. Сентябрь ае мәгълүматларына караганда, программада катнашу өчен Татарстанга 360тан артыграк гариза кергән. Парламент башлыгы чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезгә бу программаны популярлаштыру тәкъдиме белән чыкты.

Татарстанда ватандашлар белән эшләүнең тагы бер юнәлеше – аларны республиканың зур чараларына җәлеп итү. Мондый чаралар төрле илләрдә яшәүчеләр белән элемтәләрне киңәйтә һәм, Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, «халык дипломатиясе»нең үтемле чараларыннан берсе булып тора. Мәсәлән, быел Сабан туе бәйрәме Россиянең 48 төбәгендә һәм 20 чит илдә үткәрелгән. «Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кая гына бармасын, милләттәшләребез белән очрашырга, татар җәмгыятьләре активистлары белән аралашырга һәрвакыт вакыт таба», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Дәүләт Советы Рәисе фикеренчә, дөньялар шактый үзгәрде. Шуңа күрә бүген ватандашларыбыз белән эшләүне гуманитар гына түгел, икътисади яктан да үстерү мөһим. «Мондый элемтәләрне саклауга барлык тырышлыгыбызны куячакбыз. Без Россиядән китүчеләргә тарихи Ватаннарына әйләнеп кайту омтылышында теләктәшлек белдерәбез. Аларны көтәбез һәм, әлбәттә инде, ярдәм итәргә тырышабыз», – диде ул. Чыгышы ахырында Фәрит Мөхәммәтшин залга җыелган кешеләрне Халыклар бердәмлеге көне уңаеннан котлады. «Бергә булыйк!» – диде Дәүләт Советы Рәисе.

Фәрит Мөхәммәтшин Мәскәүгә эшлекле сәфәре кысасында Татарстанның Россиядәге Вәкаләтле вәкиллеге каршындагы Яшьләр советы вәкилләре белән очрашты. Очрашуда 19 вуз студентлары катнашты. Аларның күпчелеге – Татарстаннан. Әмма арада Россиянең башка төбәкләреннән – Башкортстаннан, Киров өлкәсе, Мордовия, Түбән Новгород, Ульяновскидан килүчеләр дә бар. Мәскәүнең 20ләп вузында якташлык җәмгыятьләре оештырылган. 2013 елдан бирле аларның барысы да Яшьләр советына керә.

«Без сезнең белән горурланабыз, – диде Дәүләт Советы Рәисе, студентларга мөрәҗәгать итеп. – Мәскәү вузына керү теләсә кемнең хәленнән килми, ә биредә уку тагын да авыррак». Парламент башлыгы студентларга укуларында уңышлар теләп, Татарстаннан килүчеләрнең диплом алганнан соң Казанга, республикага әйләнеп кайтачакларына ышаныч белдерде. «Татарстаннан теләсә кем үзенең республикасы турында горурлык хисләре белән сөйләргә мөмкин», – диде ул.

АЛМА БАР, САКЛАРГА УРЫН ЮК

Бакчачылык

Шәхси хуҗалыкларда җитештерелгән яшелчә, җиләк-җимеш һәм башка төрле бакча культураларының шактый өлеше череп әрәм була.

Алма турында әйткән дә юк. Узган гасыр башында үзебезне генә түгел, тирә-як төбәкләрне Идел, Кама, Чулман буенда үстерелгән алма белән сөендереп яшәгән Татарстан шәһәр-авыллары бүген ел әйләнәсе читтән алма ташый. Үстергәнне саклый алмыйча, черетеп бер зыян күрсәк, чит илдән килгән түбән сыйфатлы алманы ике бәясенә алып, акча янчыгын җиңеләйтәбез. Мондый хәлгә кайчан да булса чик куелырмы?

Авыл хуҗалыгы фәннәре докторы, 42 ел дәвамында Кама Тамагы районының Теньки һәм Лаеш районының Олы Кабан авылы бакчачылык комплексларында алмагач, чия, слива, алыча, абрикос һәм башка төр бакча культураларының генофондын саклау белән беррәттән, яңа сортларын чыгару, аларны тәрбияләүгә багышлаган Геннадий Осипов белән дә шул турыда сөйләшеп киттек.

– Элек Теньки төбәгендә яшәүчеләрнең төп кереме алма бакчасыннан булган. Рәсми мәгълүматлардан күренгәнчә, ул чорда алмагачларның саны 520 меңгә җиткән. Файдасы булмаса, тирә-як авылларда яшәүче бер кеше уртача 300 төптән артык алмагач үстермәгән булыр иде. Россиянең бик күп төбәгеннән – кайсы су юлы белән, кайсы ничек булдыра ала, шулай Тенькидан алма ташыганнар. Гасыр ахырында Татарстанда күпләп яшелчә, җиләк-җимеш, аерым алганда – алма җитештерүче унҗиде махсуслаштырылган хуҗалык бар иде. Бүген аларның берсе генә калып бара. Ел әйләнәсе җиләк-җимешне саклау, эшкәртү предприятиеләре дә әкренләп юкка чыкты, – дип борчыла тәҗрибәле бакчачы.

Хәер, республикада бүген дә алма бакчаларының гомуми мәйданы 3997 гектардан арта. Уңышы хәзер дә аз түгел. Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының әлеге тармак буенча бүлек җитәкчесе Ирек Садыйков әйтүенчә, баштагы елларда бакча культураларының гектарыннан уртача уңыш 123 центнер булса, интенсив технологияләр кулланганда, биш ел эчендә бу күрсәткеч 400 центнерга җитә.

– Бакчачылык – матди яктан файдалы тармак, – ди Татарстанның крестьян-фермер хуҗалыклары берләшмәсе җитәкчесе Камияр Байтимеров. – Соңгы елларда алга китеш бар. 2018 елдан башлап, үсентеләр сатып алуга тотылган чыгымнарның 50 процентын дәүләт үз өстенә ала. Сугару системасы булдыру өчен тотылган акчаның 70 проценты республика бюджетыннан кире кайтарыла.

Чүпрәле, Кукмара, Буа һәм кайбер башка район фермерларының йөзләрчә гектар мәйданда алма бакчалары үстерү белән шөгыльләнә башлаулары да – күңелле күренеш. Тик менә әлеге дә баягы саклау урыннары гына җитәрлек түгел. Статистика мәгълүматларына караганда, әйтик, «икенче икмәк»не саклау өчен 136 мең тонна сыйдырышлы урын әзерләнсә, фермер хуҗалыкларында җитештерелгән алма, чия кебек бакча культураларын саклау урыннарының гомуми мәйданы күпкә кимрәк – нибары 1,8 мең тоннага исәпләнгән булуы да борчу тудыра.

Безнең шартларга яраклаштырылган, озак саклану мөмкинлегенә ия булган алмагач, чия һәм башка культураларга килгәндә, шөкер, аларына да кытлык юк. Лаеш районының Олы Кабан авылы читендәге Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтының тәҗрибә кырында сортларның ниндие генә үсми. Тик менә тәҗрибә кырының да үз хәле – хәл икән шул.

– Россиянең ике дистәгә якын төбәгеннән китерелгән алмагач, чия һәм башка төрле бакча культураларының генофонды сакланучы 4 гектарлы бакчаның тирә-ягын койма белән әйләндереп аласы бар. Кыш көне – куян, җәйләрен чит кешеләр кереп зыян сала, – ди Геннадий Емельянович.

Сүз уңаеннан, профессор Геннадий Осипов тормыш иптәше, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты Зоя Андреевна белән – әлеге сортларны саклап калу, яңаларын булдыруга икесенә бергә 80 елдан артык гомерләрен багышлаган фидакарьләр. Теньки һәм Олы Кабан авылы янындагы бакчаларда алар уйлап тапкан сортлар да байтак икән. Бүген бакчачылар яратып үстерә торган 70 төр алмагач, 77 төр слива, 30 төр груша, 50 төр слива сортларының Россия Дәүләт реестрына кертелүе үзе үк күп нәрсә турында сөйли. Татарстанда мондый фидакарьләр булганда, республика халкы киләчәктә бакча культуралары белән үз-үзен генә түгел, узган гасыр башындагы кебек, илнең башка төбәкләренә дә өлеш чыгара ала.

Камил СӘГЪДӘТШИН

ЯКЫНДАГЫ АК ҖИЛКӘН

Татар әдәбияты, мәдәнияте тарихчысы, тәрҗемәче, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Лирон ХӘМИДУЛЛИНга 90 яшь тулды.

Берничә көн элек Лирон аганың өендә булып, гәпләшеп, гомер мизгелләрен күздән кичереп утырдык (вакыт-вакыт әңгәмәбезгә аның хатыны Дания апа кушылды). Керә-керешкә үк диярлек әдип миңа әле генә табадан төшкән «Ерактагы ак җилкәннәр» дигән яңа китабын бүләк итте. Әдип гомере буе татарның инде шактый еракта калган, нигездә XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында яшәгән мәшһүр һәм онытыла төшкән шәхесләрен – ак җилкәннәрен барлады. Чәчләрен көмеш сарган ил агасы – үзе дә ак җилкән ләбаса. Дөрес, якындагы ак җилкән. Күңел күзе томаланмаганнарга тынгысыз, ярсулы тормыш диңгезендә ак җилкәннәр юл күрсәтеп тора. Ак җилкәннәрен җуймаса, барлап, өйрәнеп торса, милләтебез беркайчан да бетмәячәк, югалмаячак. Әйдәгез, шул ак җилкәннәребезнең берсе булган Лирон аганың тормыш сәхифәләрен үзе белән бергәләп күздән кичерик әле.

Беренче сәхифә

1939 елның март ае башлары иде. Мин – җиденче яшькә чыккан малай. Туган авылыбызга – Ульян өлкәсенең Иске Тәгәлбуга авылына олуг артист, мәшһүр якташым, авылдашым Фәйзулла Туишев концерт куярга кайтты. Мәшһүр авылдашымның сәхнәдә виртуозларча уйнавын күргәннең соңында минем дә гармун дип саташуларымны сөйләп тә бетерерлек түгелдер. Әти, мәрхүм, минем елау-сыктауларыма түзмәде булса кирәк. Фин сугышыннан кайткач, 1940 елның җәй башында минем кулыма Самарадан өр-яңа тальян гармун кайтарып тоттырды. Әмма мин гармунчы булып китә алмадым. Өйрәтүче дә булмады. Тиздән Бөек Ватан сугышы башланды. Ике ел тулмастан, әтинең батырларча сугышып һәлак булуы турында хәбәр килде. Бер яз көнендә, чәчүлек бәрәңге җитмәгәч, ул өр-яңа тальянымны әни берничә пот бәрәңге исәбенә сатып җибәрергә мәҗбүр булды.

Икенче сәхифә

1943 елның җәендә әтинең үлгән хәбәре килде. Ноябрь аенда, миңа унбер тулгач, әнинең туган ягына – Оренбург өлкәсенең Новосергеевск районындагы Иске Актау (Иске Белогор) авылына кайтып киттек. Әнинең апасының да ире үлгән, хәбәре килгән: әйдә, кайт, биш малайны бергә тәрбияләп үстерербез, дип язган. Без – өч малай, анда – икәү. Ике мәртәбә поездданпоездга күчеп утырып, атна буе кайттык. Әни өч буханка ипи алган иде. Шул коткарды безне. Уфадан китә алмыйча тәүлек буе тордык. Дежур хатынга һәм кассирга берәр буханка ипи биргәч, безне икенче бер поездга утыртып җибәрделәр. Кинел дигән станциядә теге өченче буханка ипинең дә ярдәме тиде. 11 ноябрьдә кузгалган идек, 17сендә кайтып кердек.

Өченче сәхифә

Мәктәпне уңышлы тәмамладым. Энекәшләр кечкенә булу сәбәпле, укырга тиз генә китә алмадым. 1949 елны авылдан 460 чакрымдагы Актүбә дигән казах шәһәренә укырга киттем. Моның тарихы бик кызыклы. Безнең авылныкылар педучилищега укырга йөри иде. Мин дә шунда барып, имтихан биргән идем. Урыс теленнән «өчле» куйганнар. Очраклы рәвештә, укучылар җитмәгәнен ишетеп, Актүбәдәге тимерьюлчылар техникумына укырга барып кердем. Аны бик яхшы билгеләргә тәмамладым. Мин бетереп киткән елны анда язучы Рауль Мирхәйдәров укырга килгән.

Дүртенче сәхифә

Укып бетергәч, Орск шәһәрендә тимерьюлчылар идарәсенә бригадир булып урнаштым. Бер ел бригадир, өч ел мастер булып эшләдем. Шунысы яхшы: бригадирга шунда ук фатир бирәләр. Кичләрен Мәскәү политехника институтының Орск филиалында югары техник белем алдым. Биредә Мулланур Вахитов исемендәге атаклы китапханә бар иде. Даими шунда йөрдем. Хәтта ара-тирә тулай торакларга барып, татар шигырьләрен сөйләп, татар җырларын җырлап концерт куя идек. Армиядә хезмәт иткәндә, Актүбәдә газеталарда мәкаләләр бастыра башлаган идем. Иҗатымны Орскида да дәвам иттем. Шәһәрдә татар мәктәбе бар иде. Шунда завуч булып эшләүче авылдашым Мәрхәбә апа мине Дәрдмәндне күреп белгән кешеләр белән таныштырды. Дәрдмәнд соңгы өч елын шунда яшәгән. Хатыны Мәхүбҗамал Борнаева – шул ук Орск кешесе. Шулай итеп, Дәрдмәнд, Мирхәйдәр Фәйзи турында шактый күп мәгълүмат тупладым. Әле Мирхәйдәр Фәйзинең бер кулъязма китабын туганнарыннан алып мирасханәбезгә тапшырдым.

Бишенче сәхифә

Безнең авылда элек-электән татар һәм урыс мәктәбе, татар мәчете һәм урыс чиркәве бар иде. Елганың аръягында хәзер дә Пенза ягыннан күчерелгән урыслар яши. 1960 елны татар мәктәбен урыс мәктәбенә куштылар. Татарстаннан читтәге татар мәктәпләрен Сталин бетерде, дип ялгыш әйтәләр. Чынбарлыкта татар мәктәпләрен бетерү Хрущев заманында, 1957 елда башланды. Югары Советның 1957 елның апрель сессиясендә, милли республикалардан читтә булган авылларда мәктәпләрнең язмышын ата-аналар хәл итә, дигән карар чыгарылды. Шул ук елда өлкәдәге милли мәгариф буенча инспекторлар штаты бетерелде. Ике ел да үтмәде, өлкәдәге өч педучилищены да яптылар, Оренбург һәм Орск пединститутындагы татар, башкорт бүлекләре дә ябылды. 1960 елда бөтенесе бетте. Мин архивларга кереп, шул еллардагы газеталарны карап чыктым. Татарстан, Башкортстан, Чуашстаннан ичмасам бер депутат каршы чыксын! Менә хәзер дә татар теле дәресләрен ата-аналар теләге дигән сылтау белән кыскарталар.

Алтынчы сәхифә

1961 елны Казанга килдем. Иң әүвәл тимерьюлчыларга мөрәҗәгать иттем. Кукмарага мастер булып барырга тәкъдим иттеләр. Барасы килми. Сезгә тимерьюлчы кирәкмиме, дип трамвай-троллейбус идарәсенә барган идем. Шунда ук участок башлыгы итеп кабул иттеләр. Аннары инженер, баш инженер итеп билгеләделәр. 1966 елны партком секретаре итеп сайлап куйдылар (шушында сүзгә Дания апа кушыла. – **Авт.**). «Бервакыт Дәрвишләр бистәсендә, Сәетгалиев исемендәге мәдәният йортында Вафирә Гыйззәтуллина концерты булды. Шул концерттан соң Лирон мине озата кайтты. Бер-беребезне белә идек. Ул безне трамвай йөртүчеләр курсында укытты. Озак йөрмәдек. 1967 елның 22 октябрендә, аның туган көнендә никах укыттык та бергә тора башладык. Йөри торган кызлары бар иде. Кайчагында концертлардан соң мине озатмыйча, башканы озата китә иде. Егетләрнең холкын чамалау кыен. Ул вакытта миңа – 21 яшь, Лиронга – 35 яшь.



Минем авылга – Күнгә кыз сорарга кайткач, туганнарым, ялгышмыйсыңмы, артыннан, балаларын ияртеп, хатыны килмәсме, диде… Лирон да йоклап йөрми: «Татарстан яшьләре» газетасы каршында Гали Хуҗиев оештырган яшь язучылар түгәрәгендә йөрүче Күн авылы егете Мөхәммәт Садыйковтан («Татмедиа» җәмгыяте җитәкчесе Шамил Садыйковның әтисе) кызның нәсел-нәсәбен сораштырган була. Менә уртак тормыш коруыбызга 55 ел тула», – дип сөйли ул.

Җиденче сәхифә

Миңа Татарстан Язучылар берлегендә СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры булып уналты ел эшләү насыйп булды. Хәсән Сарьяннан башка моңарчы берсе дә Мәскәү белән юньләп эш итмәгән, аралашмаган. Югыйсә Язучылар оешмасы турыдан-туры Мәскәүдән акча ала. Язучыларның көнкүрешен, сәфәр-командировкаларын кайгырту Мәскәү аша үтә. Бик җаваплы вазыйфа, әлеге вазыйфаны синнән дә яхшырак башкаручы булмас, дип өлкән язучылар 1967 елны мине шушы эшкә күндерде. Мин аннан берлеккә ике мәртәбә машина алдым, фонд аша йөздән артык язучының торак шартларын яхшырттык. Мәскәүдә әдәби курсларда укырга мөмкинлек бар, дигәч, гариза язып, эштән киттем. Тик кемнәрнеңдер интригасы аркасында бу ниятем тормышка ашмады. Шуннан китап нәшриятына мөхәррир булып эшкә алдылар. Фондта эшләгәндә унлап рецензия язган, бер-ике китапны редакцияләп чыгарган идем. Аннан пенсиягә киттем. Берәр ел өйдә утырдым микән? Яңа ачылган Энциклопедия институтына галимнәрне, мөхәррирләрне җыя башладылар. Анда башта Рәис Даутовны алдылар. Рәис мине тәрҗемә секциясенең мөдире итеп тәкъдим иткән. Тик мин, авыру әниe не карыйсы булганга, гади фәнни хезмәткәр булып, нигездә өйдә эшләдем.

Сигезенче сәхифә

Язучылар берлегендә эшләгәндә, безгә казахлар, үзбәкләр, каракалпаклар килеп йөри иде. Мин азмы-күпме казахлар белән аралашкач, телләрен белгәч, алар белән элемтәне яхшыртуны миңа тапшырдылар. Гомумән, казах, үзбәк, каракалпак әдипләренең әсәрләрен бик теләп тәрҗемә иттем. Шулай ук татар әдәбияты үрнәкләрен тугандаш төрки телләрдә һәм урыс телендә чыгаруга күп көч куелды. Казахча «Татар повестери» җыентыгы, үзбәкчә «Йилләр вә йуллар», каракалпакча «Татар гүрриңлери» хикәя тупланмалары – әдәбиятларыбыз бәйланышларын раслаучы хезмәтләр.

Тугызынчы сәхифә

Минем хикәя-повестьларым, эссе-очеркларым байтак басылды. Төп эшчәнлегем Оренбург төбәгендә яшәп иҗат иткән шәхесләрнең, аерым алганда, Дәрдмәнднең тормыш юлын барлау-өйрәнү булды. Бөек шагыйребезнең тууына йөз ел тулганда, 1959 елда ук аның иҗаты, шигъри мирасы хакында зур сүз әйтелде. Мөхәммәт ага Гайнуллинның «Совет әдәбияты» журналында шушы уңайдан басылган мәкаләсен әйтүем. Шуннан башлап аны тәрҗемә иттеләр, чыгардылар да. Мин – аның биографиясен, тормыш юлын барлаучы. Бу җәһәттә миңа Гомәр аганың улы Зөфәр Бәширов аеруча нык булышты. 2003 елда чыгарган «Дәрдмәнд» фотоальбомы – икебезнең уртак хезмәт җимеше.

Унынчы сәхифә

Узган ике гасыр аралыгында Оренбург төбәгендә иҗат иткән кайберәүләрнең әдәби эшчәнлеге, әдәби талпынышлары күп очракта телгә дә алынмый. Шундый шәхесләрдән Габдрахман Дәүләтшин-Хөсәенев, Шакир Мөхәммәдьяров, Ярулла Вәлиев, Габдерәүф Ниязбаев, Тимерша Соловьёв-Саллави, Гомәр Каргалый, Кәбир Бәкер, Заһид Шәркый-Йосыпов, Төхфәт Ченәкәй-Самави мираслары әле һаман татар дөньясыннан читтә кала сыман. Милләтебез яңа тормышка кергән чакта шактый зур эшләр башкарган, туган телебездә яңадан-яңа газета-журналлар оештырган, милли телдә укытучы югары уку йортларын булдыруга үз өлешләрен керткән мондый бөек шәхесләребезне онытмасак иде.

Рәшит МИНҺАҖ язып алды

Радио – могҗиза

Билгеле булганча, 1927 елның 7 ноябрендә Казанда радиостанция аваз бирә. Татарстан башкаласында татар телендә радиотапшырулар башлану – мәдәни тарихыбызда зур вакыйга. Бу казанышыбызны булдыруда күренекле хәрби җитәкче, язучы Шамил Усмановның хезмәте әйтеп бетергесез зур. Бу вакытта инде Мәскәүдән һәм Ленинградтан тыш, Ташкентта, Дагыстанда, Харьковта, Түбән Новгородта җирле радиолар эшли башлаган була. Шамил уйлана: ни өчен әле радио Татарстан башкаласында да сөйләмәскә тиеш? Ул бу сорау белән иң әүвәл фирка өлкә комитетының беренче секретарена керә. Анысы Совнарком рәисенә җибәрә. Монысы, акча юк, дип җавап бирә. Монда хәл итү мөмкин булмаячагын аңлагач, Шамил Усманов Мәскәүгә, Ленинградка юнәлә. Бергә-бергә фронтларны кичкән элеккеге хәрби дуслары ярдәмендә кирәкле техник җиһазларны табуга ирешә. Казанда аларны кирәгенчә урнаштырып, эш хәленә китерерлек белгечләр таба һәм, ниһаять, 6 ноябрь көненә бөтенесе әзер була. Радиостанцияне эшләтә башлауны иртәгәсе көнгә, ягъни инкыйлабның 10 еллыгына туры китерергә телиләр. Шулай эшлиләр дә. Эфирга татарча беренче сүзне дә Шамил Усманов үзе әйтә:

– Казан сөйли!

– Татарстан башкаласы сөйли!

Казанның төрле урыннарыннан шалтыратулар башлана:

– Ишетәбез!

– Тыңлыйбыз!

– Сөйләгез!

Ләкин шунысы бар: әле татар халкының күпчелеге өчен «радио» дигән нәрсә таныш түгел. Ул нигә кирәк? Аны булдырудан ни файда? Аны ничек тыңларга була? Бу сорауларны очрашуларда да, хатлар аркылы да күп бирәләр. Шамил Усманов бу яңалык турында аңлату эшләре алып бару кирәклеген аңлый. Урыннарга барып, тыңлаучылар белән очрашулар оештыра. Мәсәлән, аның хәзерге Яшел Үзән районы Норлат авылына бер төркем иҗат кешеләре белән барганлыгы билгеле. Анда Гадел Кутуй, Фатих Сәйфи-Казанлы, Мәхмүт Бөдәйли була. Мәскәү консерваториясен тәмамлаган профессиональ җырчы, Шамил Усмановның хатыны Асия Измайлованың җырлавына авыл халкының исе китә. Егерменче еллардагы татар хатын-кызы халык көйләрен, классик әсәрләрне шулай башкарсын әле! Бу инде бөтенләй зур яңалык була.

Бер үк вакытта Шамил Усманов халыкка радио турында матбугат ярдәмендә аңлату буенча да күп эшли. Әле күптән түгел генә 1927 елда төзелгән Яңалиф җәмгыятенең «Яңалиф» дигән журналын күздән кичереп утырдым. Көтмәгәндә 1927 елдагы 11 нче санында Шамил Усмановның бер язмасына юлыктым. Ул «Яңа дәвер алдында» дигән рубрика белән бирелгән. Үтемлерәк булсын дигәндер инде, хикәя рәвешендә язылган. Сезгә шул язманы тулысынча җиткерәсем килде. Менә ул. Әсәрнең исеме юк. Эчтәлегеннән чыгып, аны «Радио – могҗиза» дип атарга мөмкин булыр иде.

Фоат ГАЛИМУЛЛИН,
КФУ профессоры, Татарстан радиосының
1960–1970 нче еллардагы дикторы

Караңгы төн. Тышта кар бураны үкерә. Табигать кемнедер ачуланган төсле котыра, авылның салам түбәле өйләрен кар таулары белән күмә. Авыл караңгыга чумган.

Бары читтәге өйләрнең берсенең тәрәзәсендә күренгән зәгыйфь кенә ут яктысы анда тормыш барлыгын белдерә. Өстәл артында икәү: берсе кара чәчле, җанлы күзле яшь, икенчесе – чәченә чал керә башлаган карт. Алларында кара шкатулкага охшаган радио аппараты, телефон трубкаларын башларына киеп утырганнар.

Тышта улаган кар бураны аларны тынычсызландырмый. Трубкадан көчле симфония оркестрының моңлы тавышы ишетелеп тора.

Яшь егет конденсатор ручкасын бора башлый. Симфония туктала. Аның урынына берәүнең көчле тавыш белән җырлавы ишетелә.

– Бу кайдан икән?

– Германиянең радио стансасы эшли. Менә хәзер Истанбул стансасын табыйк. Аннан кайчакта матур гына музыка бирәләр.

Телефонда җиңел генә сызгыру ишетелә. Конденсаторны бору белән сызгыру югала. Берәүнең төрекчә сөйләгәне ишетелә башлый.

Карт, башыннан телефонын алып, гаҗәпләнгән кыяфәт белән егеткә карый.

– Бу кайдан сөйлиләр дидең?

– Истанбулдан.

– Ул бездән дүрт мең чакрым ераклыкта ич.

– Әйе, менә хәзер Италияне эзләп табабыз. Ул тагын даераграк. Җиде мең чакрым. Ә менә хәзер Мәскәү стансасы.

Трубкадагы тавыш кинәт көчәеп китә. Икәве дә телефонны, колакларыннан салып, өстәлгә куялар. Аннан бөтен бүлмәгә ишетелерлек итеп тавыш килә:

– Алло, алло… Мәскәү сөйли. Хәзер экспериментальный театрда барган «Кармен» операсының икенче акты бетте. Биш минут перерывтан соң, өченче акт башлана. Ә хәзергә опера хакында мәгълүмат бирелер. Тыңлагыз, «Кармен» операсы.

Сәгатьтән артык ике тыңлаучы, өстәлгә таянып, баш иеп, алларындагы кечкенә трубкадан килгән тавышны тыңлыйлар.

– Алло, опера бетте. Хәзер Красная площадьны бирәм. Сәгатьләрегезне хәзерләгез.

Кремль башняларындагы курант 12не суга башлый.

Җегет:

– Ятырга вакыт инде, – диеп, аппаратын җыя башлый.

Карт, тәрәзә янына килеп, сөйләнә:

– Тышта кар бураны уйный. Йөз еллар буенча бу авыл, төннәрдә тирән йокыга чумып, бөтен дөньядан өзелеп тора иде. Ә хәзер ул дөнья белән хәбәрләшергә юл тапты.

Кар бураны! Котыра бир. Хәзер син безне куркыта алмыйсың инде.

Көчле радио сине җиңә.

Ул, йөзләп, меңләп чакрым җир үтеп, адәмчелек дөньясын бер-беренә ялгый.

(«Яңалиф». – 1927. – № 11. - 7 бит)

Авыл хәлләре

КЫШКЫ РЕЖИМНЫ КӨТКӘНДӘ

Авыл тулаем (кешеләре генә түгел) кышкы, язгы, җәйге режимнарда яши. Язгысы карлар эрү белән башланса, җәйгесе көтү чыккач, көзгесе бәрәңгеләр алгач, кышкысы кар төшкәч башлана. Якынча шулай. Аларның озынлыгы табигать шартларына бәйле. Араларында иң көтелгәне кышкы режим кебек тоела.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Көзге караңгылыктан, салкын яңгырлардан күңел дә күшеккән чорда бигрәк тә тансык ул. Беренче кар төшүгә башка елны күңелләр күтәрелеп, җаннар тынычланып китә иде. Быел үзгәрәк шул. Карлар гына әрнү-борчуларны киметерме?.. Әмма карны көткән күңел барыбер могҗиза көтә, яхшыга өметләнә.

Арада күчеш чорлары да бар. Менә әле дә авыл көздән кышка күчү чорында яши. Кышкы режим турында сүз чыкса, шаянраклар: «Нинди кыш?! Әле әбиләр чуагы да булмады бит», – ди. Дөрестән дә, быел әллә булмады ул, әллә күрми калдык шунда. Әбиләр чуагы дигән чор авылда сизелмәде. Башка елны «иртә әбиләр чуагы», «соңгы әбиләр чуагы» дигән фараз бирүчеләр дә быел никтер дәшмәде (бәлки мин ишетмәгәнмендер). Хәер, сары-чуар яфраклары белән балкып утырган, дистәләрчә көнгә сузылган җылы, матур әбиләр чуагын да, без, авылныкылар, күп чакта урамда, бакчада эшләргә рәхәт көннәр дип сөенеп кенә үткәрәбез шул. Аннан инде: «Шул яфраклар сап-сары булып утырган чакта табигатькә дә чыгып булмады», – дип уфтана күбебез. Икенче елга һич тә алай итмәбез, бөтен эшне ташлап, ярты сәгатькә генә булса да, авыллардан әллә ни ерак урнашмаган (хәзер олы юл буйларына ике яклап кардан ышыклау өчен агачлыклар утыртып бетерделәр, араларында каеннар күп – чыршылар белән чиратлашканга, көзен искитмәле булып утыралар) урман полосаларына (посадкаларга) булса да барырбыз дип җыенабыз. Яфраклар коелып беткәч, шулай дип план корсак та, тик икенче, өченче елы да шулай үтә. Каеннар арасында коры сары яфракларны кыштырдатып йөрү күпләребез өчен чынга ашмас матур бер хыял булып кала бирә…

Быел табигатьтә күп нәрсә үзгә булды. Елы елга охшамый, дисәләр дә, ул чакларда елның бер фасылы гына үзгәрәк була иде, быел башта язны, аннан җәйне көтеп үткәрдек, августта тоташ булган челләдән шактый алҗыган идек, сентябрьдә үк башланган төссез көннәр дә күпкә китте кебек. Бер эшне дә иркенләп, тәмләп, үз вакытында, тынычлап эшләп булмады. Язын һәм көзен авылда эш аеруча күп була. Һәм аларның һәркайсының үз чираты бар. Быел исә язын да, көзен дә әлеге чиратлар буталды. Язы да, көзе дә бер чама килде шул. Шуңа күрә ай буена дип планлаштырылган эшләрне аяз торган санаулы көн эчендә эшләп өлгерергә кирәк булды. Язгысында, әйдә, җәй озын әле, эшләрбез, дип юансак, хәзер инде, менә-менә суыта, туңдыра, дип, ашыгырга туры килә. Без генәмени, күмәк хуҗалыкларга да мондый яз-көз шактый кыенга туры килә. Аларда да бит барысын да үз вакытында эшләргә кирәк. Кайбер елларны инде бу вакытка барлык техниканы кышкы саклауга куеп өлгерсәләр, быел әле басуларда эш бетмәде: орлыкка дигән кукуруз-рапсның өлгерүенә кояшы, җылысы җитмәде, алар соңарды, җир эшкәртүләр дә тоткарланды. Бүген техникалар куәтле дисәң дә, һава шартлары мөмкинлек бирмәгәндә алар да берни эшли алмый шул.

Башка елны бу чорда инде, быел кыш аномаль салкын булачак икән, дип фаразлап, куркыта башлыйлар иде. Быел әле бу турыда әллә ни фикерләр ишетелми. Әллә фаразларының чынга ашмавын аңлаганнар, әллә башка сәбәп… Тик шунысы хак: табигать тә үзгә быел. Әллә шулай тоела гынамы, бөтен хикмәт күңелдәме?..

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе, әтисе

МИҢНУЛЛИН Нурислам Гарифулла улы

вафат булу сәбәпле, хезмәттәшебез Миңнуллин Рөстәм Нурислам улының, туганнарының авыр кайгысын уртаклаша.

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры коллективы, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

Николай Иванович ДУНАЕВ (Наил Дунаев)

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең туганнары, дуслары, якыннарының авыр кайгысын уртаклаша. Татар театрының талантлы артисты, сәнгатькә тугрылыклы булган дустыбыз, сәхнәдәшебезнең якты истәлеге безнең күңелләрдә мәңге сакланыр.

БЕЗДӘН СЕЗГӘ – 3 БҮЛӘК

1 **ЯЗЫЛ!** 2023 елның беренче яртыеллыгына **«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»** газетасына язылу

2 **КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!**

89179270040

info@vatantat.ru

420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 **БҮЛӘККӘ**
1. Суыткыч.
2. Микродулкынлы мич.
3. Мультиварка.

П2435 җомга саны **512 сум 70 тиен**

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга **1143 сум 96 тиен**

Акция 2022 елның 26 октябреннән башлап 2023 елның 20 гыйнварына кадәр дәвам итә. Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе. Тулырак: vatantat.ru

16+ реклама

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Уенчык

Балаларыгызга уенчыклар алыгыз. Уеннан аларны беркайчан да тыймагыз.

Сабыйлар тормышында уеннарның әһәмияте чиксез. Ул баланың психикасын ныгытуга ярдәм итә, аны үстерә, хис һәм кичерешләр байлыгын тәэмин итә. Уен вакытында бала яңа ачышлар ясый, шатлык мизгелләре кичерә, үз-үзен һәм тирә-юньдәгеләрне бәяләргә өйрәнә, дуслар таба, алар арасында үзен ничек тоту юлларын барлый. Бу аның хыял байлыгын арттыра, иҗади мөмкинлекләрен ача, фикерләү сәләтен үстерә.

Уеннардан мәхрүм калган балалар, үсә төшкәч тә, кечкенә чагында ала алмаган уен ләззәтләрен алырга омтылып яши. Үзләре дә сизмәстән, алар уенга тартыла, сабый чакларында җитмәгән хис-тойгы байлыгын, үткен кичерешләрне өлкәнәйгәч булса да татып калырга тырыша. Моны алар үзләре аңлап та бетермиләр хәтта, барысы да аң асты кимәлендә башкарыла.

Балаларыгызга уенчыклар алыгыз. Уеннан аларны беркайчан да тыймагыз.

Эш вакытында кәрт суккан кешеләр турында ишеткәнегез бармы? Юк, ялкау түгел алар. Әнә бит, ничек дәртләнеп, кәртләрен өстәлгә шапылдатып сугалар. Баржа тарткан бурлаклар шикелле ярсу авазлар чыгаралар. Җиңелсәләр, их, дип кулларын селтиләр, үз-үзләренә аптырап, башларын чайкап торалар, ә җиңсәләр, шатлыкларын эчләренә сыйдыра алмыйча кычкырып көләләр, сикергәлиләр... Нәкь менә сабый балалар инде. Мавыгып китсәләр, кичкә кадәр шулай утырырга да мөмкиннәр. Ярый әле берәр иптәшләре яки җитәкчеләре аралап кала: «Җитте сезгә! Кәрт уйнап хезмәт хакы алырга телисезме әллә? Марш эшегезгә!» Шунсыз туктый белмиләр. Ә уенның бөтен яме югала. Рәхәтләнеп уйнау өчен, эшче булырга ярамый, бригадир булырга кирәк.

И бригадирларның да уйнамый үскәннәре бар инде. Кайберләре әнә компьютерында уйнап утыра. Читтән караган кешегә эш белән мәшгуль кебек ул: уйлана, тәвәккәлләп, төймәләргә баскалый, димәк, ашыгыч карарлар кабул итә, елмаеп куя, кәнәфиенә чалкан ятып, нәрсәдер көтеп тора. Яхшы фикер килгәч, тагын кабаланып, төймәләргә баскаларга тотына һәм бик җитди эштә зур хата ясаган кыяфәт белән аһылдап, башын өстәлгә сала. Читтән караганда, бу шулкадәр булдыклы кеше, шулкадәр тырыша, җанын бирердәй булып эшли, дип торырсың. Ә ул уйнап утыра. Ләкин кинәт җитәкчесе килеп керә дә бөтен эшне боза. Тиргәп ташлый. Премия язмыйм, дип куркыта. Язмаса язмасын, тик комачаулап кына йөрмәсен иде. Юк, болай булмый. Рәхәтләнеп уйнау өчен, үзең җитәкче булырга кирәк. Җитди кеше, абруйлы кеше.

Һәртөрле казиноларда кемнәр утыра дип беләсез? Тиз генә, җиңел генә баерга теләгән ялкау кешеләрме? Юк, бала чагында тиешенчә уйный алмый калган кешеләр утыра анда. Кечкенә вакытында рәхәтләнеп уйнап үскән кешеләр җитди эшләргә омтыла, файдалы гамәлләр кылырга тырыша. Ә боларның бар максаты – уен. Хәтта үзләре зур вазыйфалар биләгән, абруй казанган бай кешеләр булсалар да. Бала чак мохтаҗлыгын алар менә шул рәвешле кайтарырга тели. Әмма азартлы уеннар уйнау – тыелган нәрсә, моның өчен беркем хөкем итмәсә дә, һәр кеше андый уенчыга кырын карый. Рәхәтләнеп уйнау өчен, абруйлы һәм бай кеше булу гына җитми. Зур кеше булырга кирәк.

Балаларыгызга уенчыклар алыгыз. Уеннан аларны беркайчан да аермагыз.

Юкса алар сезгә бик нык үпкәләячәк. Башка балалар әллә нинди затлы нәрсәләр белән уйнаганда, сезнеке бернәрсәсез калса... Ул сезгә рәнҗеячәк... Ул сезне күралмый башлаячак. Үзе белән бергә аның рәнҗүләре дә, нәфрәте дә үсә барачак. Һәм бала күңелендә сезгә карата ялралган шул нәфрәт тойгысы акрынлап кына башкаларны да күралмау хисенә әйләнәчәк.

Ә бала барысына да үч итеп яшәргә өйрәнәчәк... «Үсәм менә. Үземә үзем хуҗа булам. Күп итеп уенчыклар алам. Рәхәтләнеп уйныйм аннан соң. Беркем каршы килә алмаячак». Яхшы укыячак, алдынгылыкка, мактау-данга, югары урыннарга омтылачак. Ул үзе куйган максатларга ирешәчәк. Ләкин нинди генә югары урыннарда утырса да, уйнарга комачаулап йөрүчеләр табылачак. Һәм ул тагын да зуррак үрләргә омтылачак. Зур кеше булачак. Иң зур кеше. Чөнки иң зур кеше булгач, аны уенынннан беркем дә тыя алмый. Хәтта кемнәрдер тыярга тырышса да, ул барыбер уйнаячак... Аларны ул үзе тыячак. Һәм... уйнаячак...

Тик хәзер инде башка нәрсәләр белән уйнаячак.

Балаларыгызга уенчыклар алыгыз!

ИМӘННӘРГӘ ҖИТТЕ ЧИРАТ...

КАМАЛ ТЕАТРЫНДА ЛЕГЕНДАР ЩЕПКИНЧЫНЫ СОҢГЫ ЮЛГА ОЗАТТЫЛАР

Хуш, безнең Дунай, Николай дәдәй, Николай Иванович, Наил абый... Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты, Тукай һәм Җәлил исемендәге дәүләт премияләре лауреаты, профессор Наил (Николай) Дунаевны якыннары, дуслары, сәхнәдәшләре яратып, һәркем үзенчә искә алды.



Күренекле шәхесләрне соңгы юлга озатканда һаман саен аларны кадерләп җиткермәвебезне телгә алабыз. Татарстанның Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов та Наил Дунаевны озату мәрасимендә шул хакта әйтте.

– Камал театры сәхнәсендә тагын бер якты йолдыз сүнде. Тугрылыклы тамашачылары, сәхнәдәшләре күңелендә бу йолдыз әле озын-озак еллар янар, алар аны сагынып, юксынып яшәр. Театрыбыз сәхнәсе дә буш тормас, яшь, булдыклы артистлар килер. Әмма щепкинчылар исемен йөртә торган, 60 нчы еллар башында театрыбыз тарихына яңа дулкын булып килеп кергән, аңа яңа сулыш өргән артистларыбызның берсен соңгы юлга озату икеләтә авыр. Наил ага – алты дистә елдан артык театрның яңа тарихын язган шәхесләрнең берсе. Ул – күренекле рольләр авторы гына түгел, бөтен җаны-тәне белән 60 елдан артык шушы сәхнәдә яшәгән кеше. Наил ага, 85 яшен тутырган мәлдә, телевидение тарафыннан игътибар җитмәвен үкенеч белән телгә алган иде. Без аның бу теләген, соң булса да, тормышка ашырырбыз, билгеле. Әмма, соңарганчы, тамашачы күңеленә изге җаннар булып кереп калган шәхесләребезгә кадер-хөрмәтне, игътибарны кызганмасак иде.

Күңеле пакь иде аның... Мәрхүмне тормыш иптәше Татьяна Дунаева әнә шулай дип искә алды.

– Ул Татарстанның йөзек кашы булган театрда эшләве белән чын күңелдән горурлана иде, аның киләчәге якты булуына ышанып яшәде. Артистларга гына түгел, театрда эшләүче һәр кешегә зур ихтирам белән карады. Ихлас булды, турысын бәреп әйтте, кырыс сүз әйтүдән курыкмады. Күңеленең сафлыгы бар дөньясына җитәрлек иде...

Керәшен татарларының алтын баганасы иде! Георгий Ибушев Николай Ивановичның керәшеннәр өчен һәрьяклап терәк-таяныч булуын әйтте.

– Халкыбыз бүген сөекле улы белән хушлаша. Сөекле, чөнки аны Татарстан халкы чын күңеленнән яратты, хөрмәт итте. Һәм ул моңа чын мәгънәсендә лаек иде. Ул, кая гына барса да, безне – керәшеннәрне яхшы яктан күрсәтергә тырышты. Без оештырган бер чараны да калдырмады. Безнең арада килеп чыккан низагларны да төпле сүзе, киңәшләре белән туктата белде. Шул ук вакытта җитди һәм бераз усалрак та иде ул. Хуш, алтын баганабыз, киңәшчебез! Хуш, Николай дәдәй! – диде ул, Татарстан керәшеннәренең иҗтимагый оешмасы исеменнән якыннарының авыр кайгысын уртаклашып.

Камал театрындагы аерым бер гаилә – легендар щепкинчылар өчен «Дунай»ларының китүе аяз көндә яшен суккан кебек булган. Безнең Дунай, гомумән, авырырга тиеш түгел иде, ди Равил Шәрәфиев.

– Безнең Камал театры дигән зур гаиләбез бар. Шушы гаилә эчендә инде 62 ел буе щепкинчылар дигән кече гаилә яшәп килә. Без, щепкинчылар, шактый нык, гомерле халык булып чыктык. Әле менә шушы яшьтә дә безнең шактыебыз исән. Җитмәсә, театрда эшләп ятабыз. Бүген арабыздагы физик яткан иң нык, иң озын гомерле булыр дигән Дунаебызны озатабыз. Димәк, хәзер инде имәннәргә дә чират җиткән. Нишләтәсең бит... Дунайның авырып ятуын белгәч, бик кыен булды. Бер дә аңа килешми торган авыру иде ул. Дунай, гомумән, авырырга тиеш түгел иде. Ләкин ул эзсез китмәде, эшен җиренә җиткереп эшләп китте. Кыяфәте белән дә, күңеле белән дә матур кеше иде. Бәхил бул, Коля!..

Аның сүзен Ринат Таҗетдин дәвам итте.

– 70 яшендә дә сәхнәдә йөгереп йөргән кеше бит ул! Авыр хәлдә ятканда янына барып: «Дунай, болай яту килешми бит инде сиңа! Сине бит театрда көтәләр», – дигәч, чын күңелдән көлеп җибәрде ул. Ләкин тормыш үзенекен итә...

Якташы, сабакташы, дусты Рабит Батулла мәрхүмне ныклы холкына сокланып искә алды.

– Дунай үз эшен эшләп китте. Мөгаллим буларак та, актер буларак та, тәрҗемәче буларак та, балыкчы һәм футбол җанатары буларак та. Ул гаҗәеп үҗәт кеше иде. Һәм шушы эшләрнең барчасын да үҗәтләрчә башкарды. Күбебез театрны ташладык, башка һөнәрләргә күчтек, ә ул хыянәт итмәде. Аның бер генә хатын белән яшәве дә – үҗәтлек. Арабызда хатын алыштыргалаучылар да булды чөнки. Ә Дунайга ныклы холык бирелгән иде. Сәламәтлеге дә нык иде аның. Ләкин гомеренең соңгы 9 аенда интекте, бичаракай. Шушы вакыт эчендә булган гөнаһларын югандыр...

Рабит Батулланың сүзләрен Әсхәт Хисмәтнең җылы һәм якты хатирәләре раслады.

– 85 яше тулган көнне – 3 майда бакчага алып барып кайттым мин аны. Юл буе сөйләштек. Аның һәр сүзе – тарих бит! Аннан соң әле театрда бергә утырып концерт та карадык. Кисәк кенә авырып китте шул. Ни хастаханәгә, ни өенә бара алмадык, әллә нишләп читенсендек шунда. Хәзер менә соңгы юлга озатабыз... Галәмәт яхшы кеше иде ул. Без, яшь буын, электән щепкинчыларга, аларның бердәмлегенә, шәп итеп уйнауларына соклана идек. Оста артист кына түгел, Наил абый оста балыкчы да иде. Театрда балык белән сыйламаган кешесе калдымы икән? Иделдә балык тотканда шалтырата иде дә: «Балык ашыйсың киләме? Килсә, каршы ал мине», – ди иде. Наил абый Идел уртасыннан көймәсе белән йөзеп чыга иде, ә мин ярда каршы ала идем. Кыш көне дә кайтып кермәде балыктан. Гаҗәеп остаз да иде ул. Гомере буе яшьләрне укытты. Безгә дә: «Ялкауланмаска!» – дияргә ярата торган иде, – дип искә алды.

Наил Дунаев үзеннән соң якты эз калдырып китеп барды. Мәрхүмне Казанның Курган зиратында җирләделәр.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

КҮЗГӘ-КҮЗ

Премьера

Театр сәхнәсе – аерым кешеләр тормышын һәм артистлар уенын гына түгел, хакыйкатьне, тарихны, милләт һәм чор язмышын чагылдыра торган зур мөнбәр.

Шуны күздә тотып, Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театры бу сезонда «Театраль педагогика» проекты кысасында «Хәл бу ки...» дип исемләнгән поэтик-документаль спектакльләр сериясен башлап җибәрде.

Мәктәп дәреслекләрендә урын алган әдипләрнең тормыш юлы да, иҗаты да укучыларның күз уңына эләксә элэгә, эләкмәсә – юк. Бүген, бөтен мәгариф системасы БДИ дигән бер сүзгә текәлеп торганда, кызганыч, татар әдәбияты турындагы мәгълүмат диңгездәге бер тамчы хәлендә генә. Бу җәһәттән «Хәл бу ки... Хәсән Туфан» драмасы тамашачыларга шәхес бөеклеге, ил тарихындагы фаҗигале репрессияләр, чын мәхәббәт көче белән күзгә-күз карап очрашу мөмкинлеге бирә.

Үткән гасырның утыз җиденче еллары тарихка кара тап булып ягылган. Намус, тугрылык, дуслык дигән сүзләрнең сират күпере аша узып сыналу чоры бу. Спектакльдә әлеге сынауда иң көчлеләрдән булып кала алган Луиза Салиәскәрова образы калку итеп сурәтләнә. Ул рольне башкарган Флүзә Касаева (Татарстанның атказанган артисты) уенында «ир бирмәк – җан бирмәк» мәкале бөтен тулылыгы белән ачыла; үзенең канын (бәлки, шул сәбәпле гомерен дә) бирү бәрабәренә төрмә камерасындагы Хәсәнен ачлыктан, авырудан коткарырга омтылган Луиза йөзендә хатын-кызның рухи көче чагыла. Спектакль шагыйрьнең биографиясен чагылдыруны максат итеп куймый, шулай да режиссер һәм инсценировка авторы Олег Кинҗәгулов кулланган символлар ярдәмендә иҗат һәм язмышның чәч толымыдай бик уңышлы үрелешен күрми мөмкин түгел. Хәсән Туфанның «Бирде дөнья кирәкне...» шигыре аша олысына-кечесенә бердәй таныш алкалар – парлылыкны, кавышуны һәм мәңгелеккә аерылышуны аңлаткан символик тамгалар спектакльнең башыннан азагына кадәр тамашачының күз алдында. Залга кереп, урындыкларга утыра башлаганда ук, аларның карашы түрдә каршы алган Туфанның (Татарстанның халык артисты Рафик Каюмов) йомарланган учларында туктала. Хатынының соңгы ядкаре булып каршы алган алкалар, берадан, бикле учтан «чыгып», бәхетле бөтерелгән Луизаның колакларында чыңлый; пычрак сәяси уен корбанына әйләнгән миллионнарның челпәрәмә килгән гомере булып, өстәлдә кадерсез аунап ята; акланган һәм акланмаганнарның бәгырь сызлавы булып, кабат уч төбендә сыкрый.

Ир белән хатынның тән һәм җан бергәлеге аларның өстәл янында парлап чәй эчү күренеше аша – бик нәфис, зәвыклы алымнар белән тәкъдим ителә. Спектакльнең 12+ тамгасы белән, мәктәп балаларына да күрсәтелүен исәпкә алсаң, мондый табышка афәрин диярге генә кала. Шагыйрьне озын-озак төрмә юлы көткәненә ишарәләп, аның кулында кашык-тәлинкә төрелгән төенчек пәйда булу; коляскага иелгән ана учларыннан, кечкенә улларының үлемен аңлатып, туфрак коелу; фатирга тентү белән кергән совет хәрбиенең аяк астына кан салынган күпсанлы шешәләр тезелү – болар барысы да символлар теле белән тамашачыны уйланырга, тетрәнергә, тарихи чынбарлыкны үз йөрәге аша үткәрергә мәҗбүр итә.

Спектакльдәге һәр персонажның шәхес һәм чор сулышын чагылдыру җәһәтеннән үз йөкләмәсе, миссиясе бар. Әдәбият галиме, «халык дошманы» дип атып үтерелгән Галимҗан Нигъмәти хатыны Жанна (Татарстанның халык артисты Гөлүсә Гайнетдинова) – андый тамга сугылганнардан йөз чөермәгән тугры дусларның җыелма образы кебек. НКВД солдаты – яшь артист Фердинант Насретдинов уенында үзенең дә система корбаны икәнен төшенеп өлгермәгән салкын йөрәкле, кансыз хәрби буларак кабул ителсә, ерак Бараба далаларында яшәп ятучы Кузьма карт (Фирдүс Сафин) һәм аның килене Клавдия Петровна (Индира Маликова) кешеләрнең гап-гади бәхеткә хакы барлыгы, әмма ил һәм җир бүлешә алмаганнарның ул бәхетне бәллүр пыяладай кыеп төшерүләре хакында сөйләүче геройлар. Авылдагы ир-егетләр яу кырында кырылган, хатыннар тол, кайберләре бала сөю бәхете дә татырга өлгермәгән. Бу фаҗига аларның сөргендәге Хәсән Туфан белән әңгәмәләрендә бөтен тирәнлеге белән ярылып ята.

Персонажларның барысы да спектакль барышында Хәсән Туфан шигырьләрен укый. Шагыйрьнең «Илдә ниләр бар икән?», «Агыла да болыт агыла», «Нигә болай ашыгасың, йөрәк?», «Мин фәлсәфә чатырлары үрәм» шигырьләре дә, Борис Пастернакның «Гамлет» шигыре дә яңгырый, һәм вакыйгаларга бәйле рәвештә аларның фәлсәфи асылы тамашачыга көзгедәгедәй чагылып тәэсир итә.

Спектакль яңа форматта эшләнгән, ул театрның Кече залында бара. Кыска гына вакыт аралыгында премьераны төрле яшьтәге тамашачы күрергә өлгерде инде. Тамашадан соң ишетелгән фикерләр дә, социаль челтәрләрдәге кайтавазлар да мондый җитди спектакльләрнең бүген аеруча кирәклеге хакында сөйли. Чөнки сәхнә түреннән беркайчан да актуальлеген җуймас галиҗәнап Сүз яңгырый, шигырьләрдә гүя бүгенгебез яши...

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6697 данә
Гомуми тираж – 15337 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 362

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+